| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Альметьевского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Әлмәт авыл җирлеге советы |

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2020 ел 24 ноябрь Әлмәт авылы № 12

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2021 нче елга һәм 2022-2023 нче елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында**

"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2021 нче елга һәм 2022-2023 нче елларның планлы чорына социаль-икътисади үсеш фаразы турында» гы мәгълүматны тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2021 нче елга һәм 2022-2023 нче елларның планлы чорына социаль-икътисади үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1 нче кушымта).
2. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты Әлмәт авыл җирлегенең 2021 нче елга һәм 2022-2023 нче елларның планлы чорына социаль-икътисади үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге Советы Рәисе Д. Ә. Газизов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ОГРН 1021601312150 Совет Альметьевского сельского поселения Әлмәт авыл җирлеге Советы ИНН 1636001435

Кушымта 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенен
2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хисап | Хисап | Фараз | Фараз | Фараз | Фараз |
| Халык саны | кеше | 495 | 490 | 490 | 490 | 485 | 482 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| мөгезле эре терлекләр саны | Баш саны | 249 | 249 | 249 | 249 | 249 | 249 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Инвестицияләр | мең сум | 12800 | 3600 | 1830 | 320 | 1250 | 14000 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | -28 | -51 | -82 | +390 | +1120 |
| Торак төзелеше | кв.м. | 120 | 0 | 0 | 120 | 120 | 120 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | 0 | | | | |
| Хезмәткә түләү фонды | мең сум | 8309,3 | 8417,8 | 7996,9 | 7836,9 | 8299,3 | 8315,9 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | 1 | -5 | -2 | 6 | 1 |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум | 28853,5 | 29228,5 | 27767,0 | 27211,5 | 28817,0 | 28874,7 |
| Эшчеләр саны | кеше | 24,00 | 24,00 | 24,00 | 24,00 | 24,00 | 24,00 |
| Эшкуарлар саны (КФХ) | кеше | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 |
| Эшсезләр саны | кеше | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |

Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтеры А.В.Шириева

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразына аңлатма**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнарының статьяларын формалаштыру өчен кирәкле төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.

2021-2023 елларга Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразы, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән 2021-2023 елларга Россия Федерациясе икътисады эшчәнлегенең сценар шартларының база варианты нигезендә, Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2020 елда көтелүче нәтиҗәләрен һәм 2021-2023 елларда икътисад һәм социаль өлкә үсеше юнәлешләрен, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм индексларны кулланып, Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш вәзгыятен анализлау нигезендә эшләнгән.

2021-2023 елларда «Urals» нефтькә бәянең уртача динамикасы баррель өчен 43,3-46,5 доллар дәрәҗәсендә фаразлана.

2021 елда доллар курсы уртача еллык АКШ доллары өчен 70,8 сум, 2022 елда АКШ доллары өчен 71,1 сум булыр дип фаразлана. 2023 елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 72,4 сум тәшкил итәчәк.

Әлмәт авыл җирлеге бер торак пункттан тора: Әлмәт авылы

2021 елга Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегендә халык саны – 490 кеше, 2022 елга – 485, 2022 елга 482 кеше тәшкил итәчәк.

Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «Сарман» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең , фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның барлыкка килгән үсеш тенденцияләрен исәпкә алып, шулай ук «шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» программаларын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.

Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Сарман» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм Солтанов Р. М. КФХ эшчәнлеге алып бара.

20120 елда авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме 177 млн. сумнан артык тәшкил итәчәк. 2020 ел фаразлары буенча, продукция күләме 180 миллион сум тәшкил итәчәк, 2021 елда 1% ка артачак һәм 183млн сум тәшкил итәчәк, 2022 елда – 1% ка артачак һәм 185 млн сум тәшкил итәчәк.

2020 елда төп капиталга инвестицияләр якынча 1830 мең сум тәшкил итәчәк. 2021 елда 320 мең сум булыр дип фаразлана, 2021-2022 елларда үсеш темпы 1250 һәм 14000 мең сум булыр дип көтелә.

2021-2023 елларда 360 квадрат метр торак файдалануга тапшыру планлаштырыла.

2020 елда хезмәт хакы фонды 7,996 миллион сум тәшкил итәчәк. 2021 елга хезмәт хакы фондының фаразланган күрсәткече – 7,84 миллион сум, 2022 елда – 8,3 миллион сум, 2023 елда 8,32 миллион сум тәшкил итәчәк.

Хезмәткәрләр саны уртача 24 кеше тәшкил итә.

2020 елда уртача айлык хезмәт хакы 27767,0 сум тәшкил итәчәк. 2021 елга фараз буенча ул-27211,5 сум, 2022 елда-28817,0 сум, 2023 елда 28874,7 сум тәшкил итәчәк.

2021елга эшмәкәрләр саны 5 кеше тәшкил итәчәк, 2022 елга-5, 2023 елга-5 кеше.